| | | |
|---|---|---|
| **МИНИСТЕРСТВО ЮСТИЦИИ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН** | | **ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЮСТИЦИЯ МИНИСТРЛЫГЫ** |

**ПРИКАЗ** **БОЕРЫК**

г.Казань

**14.06.2017** **№ 01-02/50**

Эш бирүче вәкиле тарафыннан Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгында Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәренә коммерциячел булмаган оешмалар белән идарәдә бер кеше кулындагы башкарма орган сыйфатында түләүсез нигездә катнашуга яки аларның идарә коллегиаль органнары составына керүгә рөхсәт бирелү тәртибе турында

«Россия Федерациясендә дәүләт граждан хезмәте турында» 2004 елның 27 июлендәге 79-ФЗ номерлы Федераль законның 17 статьясындагы 1 өлешенең 3 пункты нигезендә **боерам:**

1. Эш бирүче вәкиле тарафыннан Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгында Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәренә коммерциячел булмаган оешмалар белән идарәдә бер кеше кулындагы башкарма орган сыйфатында түләүсез нигездә катнашуга яки аларның идарә коллегиаль органнары составына керүгә рөхсәт бирелүнең әлеге тәртибен (алга таба - Тәртип) расларга.

2. Кадрлар һәм дәүләт хезмәте бүлеге башлыгына (Т.Ю. Латыева):

Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгында Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәрләрен әлеге боерык белән таныштырырга;

Тәртипне Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгының «Коррупциягә каршы сәясәт» мәгълүмат стендына урнаштырырга.

3. Җәмәгать судьялары эшчәнлеген оештыру-хокукый тәэмин итү бүлеге башлыгына (Р.Р. Нәбиуллин) Тәртипне суд участоклары стендларына урнаштыруны оештырырга.

4. Хокукый мәгълүматлаштыру һәм компьютер системалары бүлегенә (А.Г.Сафин) әлеге боерыкны «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы Хөкүмәтенең рәсми порталында Татарстан Республикасы

Юстиция министрлыгының рәсми сайтындагы «Коррупциягә каршы тору» бүлегенә урнаштырырга.

5. Әлеге боерыкның үтәлешен тикшереп торуны үз карамагымда калдырам.

Министр Л.Ю. Глухова

Татарстан Республикасы
юстиция министрының
14.06.2017 № 01-02/50
боерыгы белән расланган

Эш бирүче вәкиле тарафыннан Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгында Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәренә коммерциячел булмаган оешмалар белән идарәдә бер кеше кулындагы башкарма орган сыйфатында түләүсез нигездә катнашуга яки аларның идарә коллегиаль органнары составына керүгә рөхсәт бирелү тәртибе

1. Эш бирүче вәкиле тарафыннан Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгында Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәренә коммерциячел булмаган оешмалар белән идарәдә бер кеше кулындагы башкарма орган сыйфатында түләүсез нигездә катнашуга яки аларның идарә коллегиаль органнары составына керүгә рөхсәт бирелү тәртибе (алга таба – Тәртип) «Россия Федерациясендә дәүләт граждан хезмәте турында» 2004 елның 27 июлендәге 79-ФЗ номерлы Федераль законның 17 статьясындагы 1 өлешенең 3 пункты нигезендә эшләнгән.

Әлеге Тәртип Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгында Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәренә (алга таба – граждан хезмәткәрләре, Министрлык) иҗтимагый оешма, торак, торак-төзелеш, гараж кооперативы, бакчачылык, яшелчәчелек, дача кулланучылар кооперативы, күчемсез милек милекчеләре иптәшлеге (алга таба – коммерциячел булмаган оешмалар) белән идарәдә бер кеше кулындагы башкарма орган сыйфатында түләүсез нигездә катнашуга яки аларның идарә коллегиаль органнары составына керүгә рөхсәт бирелү процедурасын регламентлый.

Әлеге Тәртип Министрлыктагы алар өчен эш бирүче вәкиле булып Татарстан Республикасы юстиция министры (алга таба – министр) торган Татарстан Республикасы граждан хезмәткәрләренә кагыла.

2. Коммерциячел булмаган оешмалар белән идарәдә бер кеше кулындагы башкарма орган сыйфатында түләүсез нигездә катнашуга яки аларның идарә коллегиаль органнары составына керүгә рөхсәт бирелүгә гариза (алга таба – Гариза) граждан хезмәткәре тарафыннан әлеге Тәртипкә 1 нче кушымта нигезендә язма формада бирелә.

3. Граждан хезмәткәре Гаризаны коррупцион һәм башка төр хокук бозуларны профилактикалау эше өчен җаваплы затка (алга таба - Җаваплы зат) тапшыра.

4. Җапавлы зат Гаризаны кергән көнендә әлеге Тәртипкә 2 нче кушымта нигезендәге форма буенча, Журналга терки.

5. Җаваплы зат Гаризаны алдан карау эшен гамәлгә ашыра һәм аның нәтиҗәләре буенча йомгаклау әзерли.

Гаризаны алдан карау барышында Җаваплы зат Гаризаны бирүче граждан хезмәткәреннән коммерциячел булмаган оешма белән идарәдә планлаштырыла торган катнашу функцияләрен билгеләүче язмача аңлатмалар һәм документларны соратып алырга хокуклы.

Йомгаклауда граждан хезмәткәренә коммерциячел булмаган оешмалар белән идарәдә бер кеше кулындагы башкарма орган сыйфатында түләүсез нигездә катнашуга яки аларның идарә коллегиаль органнары составына керүгә рөхсәт бирү яки рөхсәт бирүдән баш тарту турындагы җөмлә булырга тиеш.

6. Гариза теркәлгән көннән соңгы биш эш көненнән дә соңга калмыйча, Җаваплы зат Йомгаклау һәм башка материаллар (булган очракта) теркәлгән Гаризаны, коммерциячел булмаган оешмалар белән идарәдә бер кеше кулындагы башкарма орган сыйфатында түләүсез нигездә катнашуга яки аларның идарә коллегиаль органнары составына керүгә рөхсәт бирү яки рөхсәт бирүдән баш тарту турында карар кабул итәр алдыннан карар өчен министрга (аның вазыйфаларын башкаручы затка) тапшыра.

Министр (аның вазыйфаларын башкаручы зат) карарны Гариза алынган көннән соңгы ике эш көне эчендә кабул итә.

7. Җаваплы зат министр (аның вазыйфаларын башкаручы зат) тарафыннан карар кабул ителгәннән соңгы ике эш көне эчендә граждан хезмәткәренә Гаризаны карау нәтиҗәләре турында хәбәр итә һәм аңа Гаризаның министр имзасы салынган һәм кадрлар һәм дәүләт хезмәте бүлеге печате сугылган күчермәсен имза куйдырып тапшыра. Гаризаның министр имзасы салынган төп нөсхәсе граждан хезмәткәренең шәхси делосына теркәлә.

---

Эш бирүче вәкиле тарафыннан Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгында Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәренә коммерциячел булмаган оешмалар белән идарәдә бер кеше кулындагы башкарма орган сыйфатында түләүсез нигездә катнашуга яки аларның идарә коллегиаль органнары составына керүгә рөхсәт бирелү тәртибенә 1 нче кушымта

Татарстан Республикасы
юстиция министрына

___________________________________

___________________________________

(Ф.И.Ә.и., вазыйфасы һәм структур бүлекчәсе,

___________________________________

яшәү урыны адресы,

___________________________________

телефон номеры)

Эш бирүче вәкиле тарафыннан Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгында Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәренә коммерциячел булмаган оешмалар белән идарәдә бер кеше кулындагы башкарма орган сыйфатында түләүсез нигездә катнашуга яки аларның идарә коллегиаль органнары составына керүгә рөхсәт бирелү турында
гариза

Миңа түләүсез нигездә
_______________________________________________________________________________

_____________.

(бер кеше кулындагы башкарма органның яки идарә коллегиаль органының исеме)

сыйфатында идарә эшендә катнашырга, идарә коллегиаль органы составына керергә (кирәклесенең астына сызарга)

_____________________________________________________________

(иҗтимагый оешманың, торак,

_______________________________________________________________________________

торак-төзелеш, гараж кооперативы, бакчачылык, яшелчәчелек,

_______________________________________________________________________________

_________________________________

дача кулланучылар кооперативы, күчемсез милек милекчеләре иптәшлеге исеме) рөхсәт бирүегезне сорыйм.

_______________ _________________ ______________________________

(дата) (имза) (фамилия, инициаллар)

Эш бирүче вәкиле тарафыннан Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгында Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәренә коммерциячел булмаган оешмалар белән идарәдә бер кеше кулындагы башкарма орган сыйфатында түләүсез нигездә катнашуга яки аларның идарә коллегиаль органнары составына керүгә рөхсәт бирелү тәртибенә 2 нче кушымта

Эш бирүче вәкиле тарафыннан Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгында Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәренә коммерциячел булмаган оешмалар белән идарәдә бер кеше кулындагы башкарма орган сыйфатында түләүсез нигездә катнашуга яки аларның идарә коллегиаль органнары составына керүгә рөхсәт бирелү турындагы гаризаларны теркәү
ЖУРНАЛЫ

| № п/п | Дата | Ходатайство бирүченең Ф.И.Ә.и., вазыйфасы | Ходатайство бирүченең имзасы | Теркәүченең Ф.И.Ә.и. | Теркәүченең имзасы |
|---|---|---|---|---|---|
| | | | | | |
| | | | | | |